**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6687**
**14.11.2018**

Башкарма комитетның 2013 елның 1 октябрендәге 5907 нче карары белән расланган опекага алынган затның мөлкәте белән килешүләрне гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 1 октябрендәге 5907 нче карары белән (Башкарма комитетның 2017 елның 3 октябрендәге 5910 нчы карары редакциясендә) расланган опекага алынган затның мөлкәте белән килешүләрне гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктның 14 абзацындагы «2007 елның 19 февралендәге 150 нче» сүзләрен «2014 елның 11 мартындагы 147-р санлы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5.1 пунктта:

- 3 пунктчадагы «каралмаган документларны» сүзләрен «тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә эшләрне гамәлгә ашыруны» сүзләренә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге сигезенче, тугызынчы һәм унынчы пунктчалар белән тулыландырырга:

«8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән, 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән мәгълүматны таләп итү.»;

3) 5.8 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче һәм өченче абзацлар белән тулыландырырга:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән җавапта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, КФҮ яисә 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин